**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 27 августы** **№ 146**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2009 елның 19 июнендәге “«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Мактаулы гражданин» исеме турында Нигезләмәсе хакында” 235 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Кама Тамгы муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2009 елның 19 июнендәге 235 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Мактаулы гражданин» исеме турында Нигезләмәсенә (алда – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.3. Мактаулы граңданин исеме Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының карары белән бирелә.”;

1.2. Нигезләмәнең 1.8 пунктында “Башлыгы карары” сүзләрен “Совет карары” сүзләренә алыштырырга;

1.3. Нигезләмәнең 1.10 пунктында “Башлыгы карары белән” сүзләрен “Совет карары белән” сүзләренә алыштырырга;

1.4. Нигезләмәнең 2.4 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Районның бүләкләү комиссиясе карары район Башлыгына җибәрелә. Район Башлыгы районның бүләкләү комиссиясе карары нигезендә Мактаулы гражданин исеме бирелү хакындагы сорауны карау өчен Кама Тамагы муниципаль районы Советы утырышына кертә.”.

2. Әлеге карарны "Волжские зори” (“Идел таңнары”) район газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Башлыгы, Кама Тамагы**
**муниципаль районы Советы рәисе** **П.Н. Лоханов**